**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

_________ ПГ-11 14.03.2025 № _____

Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 01 февралендәге ПГ-5 номерлы «Актаныш муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указы белән, норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Нигезләмәнең 1.3 пунктында «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Нигезләмәнең 4.3 пунктында «Комиссия рәисе булып Актаныш муниципаль районы Башлыгы тора» җөмләсенә «яисә аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат» сүзләрен өстәргә.

3. Нигезләмәнең 4 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.8 пунктын өстәргә: «комиссия әгъзасы вәкаләтләрен башка затка тапшыру рөхсәт ителми».

4. Нигезләмәнең 5.10 пунктының а пунктчасына «комиссия утырышы беркетмәсен алып бара» сүзләрен өстәргә.

5. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм http://pravo/tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Л.Р.Зарипов